**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**№ 29** **Ютазы ав.** **«18» октябрь 2023 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 2023 елның 18 июлендәге 17 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен һәм гражданнарны шәхси кабул итүне карау тәртибе һәм вакытлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль законга, 2006 елның 2 маендагы «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»гы 59-ФЗ санлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 2023 елның 18 июлендәге 17 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен һәм гражданнарны шәхси кабул итүне карау тәртибе һәм сроклары турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Нигезләмәнең 8.4 пунктын түбәндәге редакциядә игълан итәргә:

«8.4. Мөрәҗәгатькә җавап электрон документ рәвешендә җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча яисә гражданның Бердәм порталдагы шәхси кабинетының адресы (уникаль идентификаторы) буенча һәм язма рәвештә, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә мөрәҗәгать иткән почта адресы буенча җибәрелә. Моннан тыш, тәкъдим, гариза яисә шикаять булган, билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагыла торган җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгатькә, аерым алганда, билгесез затлар даирәсенә карата чыгарылган суд карарына шикаять бирелә торган мөрәҗәгатькә, шул исәптән суд карарын шикаять итү тәртибен аңлатуга карата, җавап Федераль законның 6 маддәсендәге 2 өлеше һәм Татарстан Республикасы Законының 9 маддәсендәге 2 өлеше таләпләрен үтәгән килеш рәсми рәвештә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин.

1.2.Нигезләмәнең 6.3. пунктын түбәндәге редакциядә игълан итәргә:

«6.3. Электрон документ рәвешендә җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгать Федераль законда һәм Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта) мәҗбүри рәвештә күрсәтә, шулай ук электрон почта адресын күрсәтә йә Бердәм порталда шәхси кабинетның адресын (уникаль идентификатор) файдалана, аның буенча җавап, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамә җибәрелергә тиеш. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон формада кушып бирергә хокуклы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында тъбщндщге электрон адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә тъбщндщге электрон адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Л.М.Хәйруллина

